Укытучы елы

2010

*Укытучы – белем,*
*моң язың,*
*Кеше микән*
*олы остазың.*

**Мәхмүт Хөсәен**

“Җир йөзендәге иң-иң матур теләкләрне кемгә багышларга дип сорасалар, мин, башымны иеп , үзенә бик күп йөрәкләрне әсир иткән Укытучыга диярь идем ”.

(Лена Шагыйрьҗан)

“Укытучылар һәм мәктәп хезмәткәрләре – сезнең эшегезне дөрес юлга куючылар. Шуның өчен аларның әмерләрен җиренә җиткереп үтәгез, тыйган эшләренә якын бармагыз” .

(Риза Фәхретдин)

“Укытучы һәм тәрбияче булып туарга кирәк; алар белән тумыштан бирелгән сәләт идарә итә”

(Лев Толстой )

Тема:

# Ия белән хәбәр арасында сызык

# Максат:

1. Җөмлә кисәкләре турында белемнәрне актуальләштерү; ия белән хәбәр арасында сызык кую очракларын тикшерү .

2.Укучыларның телдән сөйләм осталыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү.

3. Укытучыларга карата игътибарлылык, ихтирам һәм алар белән горурлану хисе тәрбияләү.

- Белем - бәхет ачкычы, дәрәҗәнең баскычы.
- Уку – энә белән кое казу.
- Сүз – күңелнең көзгесе.
- Хезмәте каты – җимеше татлы.
- Китап - белем чишмәсе.

# Ия белән хәбәр арасына сызык кую очраклары

**Җөмләнең хәбәре баш килештәге исем, сан, алмашлык һәм исем фигыль белән бирелсә, ия белән хәбәр арасына сызык куела.**

***Мәсәлән:*** ***1) Бар булган һөнәрләрнең башы – укытучы.***

***2) Ул – тәҗрибәле белгеч.***

**Хәбәр составында төрле көчәйткеч кисәкчәләр дә булырга мөмкин. Сызык бу очракта да куела.**

***Мәсәлән:*** ***1)*** **Яз – яз инде ул.**

***2)*** **Шигърият - үзе җыр ул.**

**Искәрмә!**

**Ия күрсәтү алмашлыгы белән белдерелеп, хәбәрдән соң килсә, сызык куелмый:** ***Әтиемнең иң олы апасы бу.***

**Исем хәбәргә ярдәмче фигыль яки кисәкчә, бәйлек өстәлеп килсә, ия белән хәбәр арасына шулай ук сызык куелмый:**

***Иң кадерле нигъмәт су икән.***

арасында сызык куярлык итеп җөмләләр төзергә.

**1 вариант:** 2010 , Укытучы , ата-ана, тәрбияләү, бурыч;

**2 вариант:** көз, вакыт, муллык, хезмәт, җимеш, тырышлык;

**3 вариант:** урман, һава, чыганак, табигать, туган як, гүзәл;

**4 вариант:** бәйрәм, Сабантуй, мәйдан, милли көрәш.

Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзегез, тыныш билгеләрен куегыз һәм ия – хәбәрнең асларына сызыгыз.

**1) байлык, ул,  вакыт, хәзинә.**

**2) рухи, тел, дәвасы, ул, халыкның.**

**3) милли балетына, берсе, Фәрит Яруллин, нигез салучыларның, татар.**

**4) иң беренче, милләтне, тел, милләт иткән.**

**5) татар, нигез салучы, Салих Сәйдәшев, композитор профессиональ,    музыкасына .**

# Тест тикшерү

1. *Безнең бабай бик юмарт.* җөмләсендә хәбәр нинди төргә керә.

А) фигыль хәбәр

Б) сан хәбәр

Ә) исем хәбәр

В) сыйфат хәбәр

2. *Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.* җөмләсенең баш кисәкләре...

А) кадерләгән халык

Б) халык кадерле

Ә) телен кадерләгән

В) халык кадерле булыр

3. *Китап - бакча ул , андагы язулар – шул бакчаның гөлләре.* җөмләсендә хәбәр - ...

А) парлы

Б) кушма

Ә) гади

В ) тезмә

**4. Кайсы җөмләдә сызык (–) куела?**

**А) Су ( ) дөньяның иң кыйммәтле байлыгы.**

**Ә) Без ( ) сигезенче сыйныф укучылары ( ) төрле югары уку йортларына укырга керергә әзерләнәбез.**

**Б) Дусты бүләк иткән китап аңа ( ) ягъни Маратка () бик ошады.**

**В) Югарыда ( ) агач башларында () салават күпере күренә.**

**5. Кайсы җөмләдә сызык (–) куелмый?**

**А) Тел ул () халыкның рухи дәвасы.**

**Ә) Бу () минем өчен() бик кызыклы һөнәр булып тоелды.**

**Б) Укытучы һөнәре () мактаулы һәм җаваплы һөнәр.**

**В) Ялган сөйләү,гайбәт, саранлык, ялкаулык () тискәре сыйфатлар.**

# Җаваплар




1- Ә

2- В

3- Ә

4- А

5- Ә



# Укытучым

*Сез дөньяда- иң белемле кеше,*
*Сезнең дәрес- тормыш ачкычы.*
*Иксез-чиксез фәннәр киңлегендә*
*Маяк бит Сез, әйдәп баручы.*

*Дөньяда Сез - иң таләпчән кеше*
*Таләпчәнлек – тәртип юлдашы.*
*Тәртип булган җирдә тормыш ма*
*Зур уңышка ачыла юл башы.*

*Безнең өчен Сез - иң ягымлы кеше,*
*Йомшак сүзле, изге күңелле.*
*Белем орлыкларын җайлап кына,*
*Өләшүче дә ул - Сез түгелме!?.*

*Кайгыртучан да Сез, ә без һаман,*
*Мәшәкатьләр табып торабыз.*
*Мәктәптә Сез - икенче әни безгә,*
*Әни булгач, тыныч дөньябыз.*

*Белемле дә, кайгыртучан да Сез,*
*Таләпчән дә, һәрчак ягымлы.*
*Күңел күгемдә Сез Укытучым-*
*Йөрәгемә иң-иң якыны.*